БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» 08 2026 ел № 238

Махсус хәрби операциядә катнашучы граждапнарның гаиләләренә, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә алган хәрби җәрәхәт аркасында инвалид калган гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә халыкны яклау һәм социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү чаралары турында» 2022 елның 16 мартындагы 121 номерлы Указы нигезендә, махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә алган хәрби җәрәхәт аркасында инвалид калган гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2025 елның 30 гыйнварендагы 63 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

- 1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагында булган оешмаларның спорт объектларына - тренажер залы булган өсте ябулы «Дулкын» йөзү бассейнына, «Балтач-Арена» боз сараена («БАЛТАЧ» спорт мәктәбе» МБУ ДО) һәм спорт залларына түләүсез керү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 12 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйрстдинов